| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
| 05.06.2026 | Казан ш. | № 648-пр |

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәкъдим ителгән административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 12.05.2023 № 319-пр;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган милекне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, шәхси мөлкәткә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 12.05.2023 № 319-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек

субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган милекне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, шәхси мөлкәткә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында" 05.06.2024 № 341-пр.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И. Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
05.06.2026 № 648-пр
боерыгы белән расланган

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

Шартлы билгеләр һәм кыскартмалар исемлеге бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

1.2. Гариза бирүчеләр булып юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр - «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге һәм кече, урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 22 июль, ФЗ-159 Федераль законның (алга таба - Федераль закон № 159-ФЗ) 3 статьясы белән билгеләнгән таләпләргә туры килгән, Татарстан Республикасы мөлкәте булган күчемле һәм күчемсез милект арендаторы булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (алга таба – гариза бирүче).

Гариза бирүчеләр мәнфәгатьләре буенча тиешле тәртиптә формалаштырылган ышанычнамә нигезендә тиешле вәкаләтләр бирелгән затлар (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) эш йөртә ала.

Гариза бирүчеләрнең категория идентификаторы (билгеләре) бу Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән.

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчегә гариза бирүченең категорияләренә (билгеләренә) туры китереп күрсәтелә, аның турында белешмәләр “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры” федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – хезмәтләр реестры, Бердәм портал) урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы.

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Министрлыкның мөлкәт идарәсенең арендалау һәм дәүләт мөлкәтен реализацияләү бүлеге (алга ба – Бүлек).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне сату-алу шартнамәсе (алга таба - сату-алу шартнамәсе) белән бергә Татарстан Республикасы милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган мөлкәтне приватизацияләү шартлары турында карар (приватизацияләү шартлары турында карар әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән форма буенча).

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (приватизацияләүдән баш тарту турында карар әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән форма буенча).

Приватизация шартлары турында карар, приватизациядән баш тарту турында карар Министрлык бланкында карар формасында формалаштырыла.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында мәгълүмат системасында реестр язуы формалаштыру каралмаган.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерүне гариза бирүче үзе сайлаган ысул буенча ала:

гариза бирүченең шәхсән үзенә язмача яки электрон документ формасында;

электрон документ формасында гариза бирүченең “Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләре порталы”нда (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба - Республика порталы), “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмати система” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы http://lk.eisestate.tatar.ru (алга таба - ЕИС «Имущество») шәхси кабинетына;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба - МФЦ) Министрлыктан җибәрелгән, кәгазьгә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документ экземпляры формасында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу өчен гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашыру турында гариза (алга таба – гариза) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче (гариза бирүче вәкиле) тарафыннан шәхсән яисә почта аша бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы кергән гариза теркәлгән көннән алып 24 эш көне тәшкил итә.

2.4.2. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинет аша бирелгән булса, гаризага эш номенклатурасына туры китереп номер һәм Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетта күренеп торучы «Документларны тикшерү» статусы куелган көннән соң 24 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.3. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан МФЦ аша бирелгән булса, дәүләт хезмәте, МФЦ Регламентында каралган срокны да истә тотып, 24 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган һәм Татарстан Республикасы милкендә булган приватизацияләнә торган мөлкәтне бәяләү срогы һәм гариза бирүченең сату-алу шартнамәсен имзалау вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү срогына керми.

2.4.5. Министрлыкта һәм МФЦда дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

2.4.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гариза бирүче күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән электрон документ рәвешендә җибәрү дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Бердәм порталны, Республика порталын, ЕИС «Имущество»ны, Министрлыкның рәсми сайтын кулланган башка түләүләр каралмаган. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза биргәндә максималь көтү вакыты - 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда алдан язылу буенча килеп чиратны максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә чират тәртипләре билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросын регистрацияләү срогы

2.7.1. Гариза бирүче яки аның вәкиле тарафыннан МФЦ аша бирелгән запрос МФЦдан кергән көнне Министрлык тарафыннан регистрацияләнә.

Гариза бирүче МФЦга шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, шул көнне аңа АИС МФЦның Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаның җибәрелүен раслаган һәм электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән регистрация номерлы расписка бирелә.

2.7.2. Гариза Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша юлланса, гариза бирүче гариза бирелгән көнне Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетына һәм электрон почта белән гариза җибәрелүен раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү ала.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә.

2.7.3. Гариза почта аша юлланса, гариза бирүчегә гариза Министрлыкка кергән көнне электрон почта белән гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү юллана.

2.7.4. Гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, гариза бирелгән көнне министрлык хезмәткәре гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән расписка бирә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр Министрлыкның рәсми сайтына, Бердәм порталга, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.9. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре

Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре Министрлыкның рәсми сайтына, Бердәм порталга, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт хезмәтен МФЦларда күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә мәгълүмат алу турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Гариза бирүче шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша Бүлеккә мөрәҗәгать итсә, гариза бирүчегә консультация бирелә ала.

2.10.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, гариза бирү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү өлешендә, теләсә кайсы МФЦда, үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда, мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына яки фактта яшәгән (торган) (физик затлар өчен, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп) яисә урнашкан урынына карамастан (юридик затлар өчен) сайлавы буенча экстерриториаль принцип буенча гамәлгә ашырыла.

2.10.4. МФЦда дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге каралган.

2.10.5. Мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) МФЦда дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәләре буенча күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документлар бирү каралган.

2.10.6. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында, ЕИС «Имущество»да урнаштырылган мәгълүматны алу;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон образлары «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр оештыру турында» № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының $7^2$ пунктындагы 1 кисәгенә туры китереп алдарак расланган

документлар һәм мәгълүматны Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша тапшыру;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән запросның үтәлеше турында белешмә алу;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алу;

е) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата дәүләт хезмәте күрсәтү органнарының, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү процессын тәэмин итүче Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять итү.

Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда, Республика порталында, ЕИС «Имущество»да электрон формада запрос тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла, башка төрле формада өстәмә гариза бирү зарурлыгы юк.

2.10.7. Гариза формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган гариза һәм башка документларны күчерү һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүченең бердәм гариза юллавы күзаллаган хезмәтләр буенча мөрәҗәгать иткәндә берничә гариза бирүче тарафыннан запросның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьгә бастыру мөмкинлеге;

4) гариза бирүченең электрон формага алдарак керткән билгеләрен гариза бирүче теләге белән теләсә кайсы мизгелдә саклау мөмкинлеге, шул исәптән, кертү хаталары киткәндә һәм электрон формага әйләнеп кайтып билгеләрне кабат кертү зарурлыгы туганда;

5) гаризаның электрон форма юлларын ЕСИАга урнаштырылган белешмәне кулланып, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы белешмәне кулланып кертә башлаганчы кертә алу, шул исәптән, идентификация һәм аутентификация бердәм системасында булмаган белешмәләргә кагылышлысын да;

6) алдан кертелгән мәгълүматны югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

7) гариза бирүченең бер ел дәвамында алдан бирелгән запросларга керә алуы, шулай ук, 3 ай дәвамында - өлешчә формалаштырылган гаризаларга да.

2.10.8. Гариза бирүчеләрнең Министрлыкка, МФЦга кабул ителүгә язылуы (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», Министрлык телефоны, МФЦның контакт үзәге аша башкарыла.

Гариза бирүче Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигы чикләрендә билгеләнгән теләсә кайсы бу датада һәм вакытта язылу мөмкинлеге бирелә.

Алдан язылганда гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматка туры килмәсә, алдан язылу юкка чыгарыла.

Алдан язылганда гариза бирүчегә раслау талонын бастыру мөмкинлеге бирлә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, алдан язылу датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән мәгълүмат аның почтасына юллана.

Алдан язылганда гариза бирүчегә билгеләнгән вакытка 15 минутка соңга калса, алдан язылган вакыт юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Гариза бирүчедән Россия Федерациясе хокукый актларына туры китереп идентификация һәм аутентификация үтүдән, кабул ителү максатын күрсәтүдән тыш, шулай ук, кабул итү өчен кирәкле вакыт интервалын броньлау өчен кирәкле мәгълүматтан башкасын таләп итү тыела.

Алдан язылмау гариза бирүчегә чират тәртибендә мөрәҗәгать итәргә каршылык тудырмый.

2.10.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртипләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә “Бердәм ведомствоара электрон арадашлык системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.11. Әлеге Регламентның көче түбәндәгеләргә кагылмый:

1) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсеше турында» 2007 елның 24 июлендәге № 209-ФЗ Федераль законның 15 статьясына (алга таба - № 209-ФЗ Федераль закон) туры китереп, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга тапшырылган арендаланган мөлкәтне тартып алганда килеп чыккан мөнәсәбәтләр:

2) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләрнең мөлкәти комплексларын приватизацияләгәндә килеп чыккан мөнәсәбәтләр;

3) оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә караган күчемле һәм күчемсез мөлкәт;

4) әйләнеше чикләнгән күчемле һәм күчемсез мөлкәт;

5) кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты арендалаган мөлкәтне алу өчен өстенлекле хокукын гамәлгә ашыру гаризасын (алга таба – гариза) биргән көнне әлеге мөлкәтне торгларда сату турында белдерү басылган яки әлеге мөлкәтнең унитар предприятие тарафыннан тартып алынуын караган шартнамә төзелгән Татарстан Республикасы милкендә булган күчемле һәм күчемсез мөлкәт;

6) № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясының 4 кисәгенә туры китереп расланган Татарстан Республикасы милкендә булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары карамагына һәм (яки) куллануга бирүгә тәгаенләнгән исемлеккә кертелмәгән Татарстан Республикасы мөлкәте булган күчемле мөлкәт.

2.10.12. Составы һәм төрләре 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән арендалана торган мөлкәт, күчемле мөлкәт сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектларына милеккә бирелергә тиеш түгел.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларның тулы исемлеге

2.11.1. Законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән: алар мөрәҗәгать итүче үзе мөстәкыйль тапшырырга тиешле документларга һәм мәгълүматка, һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшыра алган документларга бүленә.

2.11.2. Гариза формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен, һәм аларны гариза бирүчегә кайтару өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) документларны башка вәкаләтле органга тапшыру - гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү кермәгән органга бирелгән

2) әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау.

3) гариза бирүче тапшырган документлар (шәхесне раслаучы документлар, вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документлар) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән моментка көчен югалткан;

4) гариза бирүче тапшырган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистартулар һәм төзәтүләр бар;

5) электрон формада тапшырылган документларда бозылган урыннар булуы хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматны тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми;

6) гариза формасында юлларның тулысынча тутырылмавы, шул исәптән, Бердәм порталда, Республика порталындагы интерактив формадагы гаризаны.

2.12.2. Законнарда дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Түбәндә күрсәтелгән шартларның берсенең генә булуы да дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

1) гариза бирүче хезмәт күрсәтелү хокукына ия булган затлар рәтенә керми, шул исәптән, № 159-ФЗ Федераль законның 3 статьясы белән билгеләнгән таләпләргә туы килми;

2) хезмәт күрсәтү турындагы запроста күрсәтелгән мәгълүматлар күчемсез милек арендасы шартнамәсендәге мәгълүматка туры килми;

3) гариза бирүченең вәкаләтле идарә органының арендаланган мөлкәтне милеккә алу карары булмау;

4) гариза бирүче (юридик зат – акционерлык җәмгыяте) тапшырган акционерлар реестры өземтәсе акционерлар һәм аларның өлешләре турында мәгълүмат бирми;

5) запрос вәкаләтле булмаган зат тарафыннан тапшырылган;

6) арендаланган мөлкәт кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты гариза биргән көнне андый мөлкәткә шартнамә яки шартнамәләр нигезендә күчемсез милек өчен - ике ел яки аннан да күбрәк вакытта, күчемле милек өчен бер ел яки аннан да күбрәк вакытта аның вакытлыча кул астында һәм файдалануында яки вакытлыча файдалануда булса (каралган күчемсез яки күчемле милек кече яки урта эшмәкәрлек субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән, № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясында 4 кисәге буенча расланган исемлеккә кертелмәгән очракларда);

7) арендаланган мөлкәт № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясында 4 кисәге буенча расланган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты гариза биргән көннән башлап күчемсез милек өчен – биш ел, күчемле милек өчен гариза биргәннән соң өч елга кадәр кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек итеп һәм (яки) файдалануга бирергә билгеләнгән исемлеккә кертелгән;

8) № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясында 4 кисәге буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек итеп һәм (яки) файдалануга бирергә билгеләнгән исемлектә арендаланган мөлкәт мөнәсәбәтле әлеге мөлкәтне № 159-ФЗ Федераль законның 2 статьясында 4 кисәгендә күрсәтелгән мөлкәткә кертелүе турында белешмә бар;

9) гариза бирүче мөрәҗәгать иткән моментка № 159-ФЗ Федераль законның 4 статьясында 9 кисәгендә күрсәтелгән мөлкәтне алу хокукын югалткан;

10) күчемсез яки күчемле мөлкәт объекты № 159-ФЗ Федераль законның 1 статьясының 2 кисәге белән билгеләнгән чикләүләргә туры килә;

11) гариза бирүченең арендаланган милекне алуга өстенлекле хокукларын гамәлгә ашыру турында гариза бирү көнендә (күрсәтелгән күчемле, күчемсез милек № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясында 4 кисәге буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек итеп һәм (яки) файдалануга бирергә билгеләнгән дәүләт милке исемлегенә кертелгән очракта), арендаланган мөлкәтне сату-алу шартнамәсе төзелгән көндә (күрсәтелгән күчемле, күчемсез милек № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясында 4 кисәге буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек итеп һәм (яки) файдалануга бирергә билгеләнгән дәүләт милке исемлегенә кертелмәгән очракта) күчемле һәм күчемсез милекне арендалау түләве буенча, вакытында түләмәү (штрафлар, пенялар) бурычлары бар;

12) җир кишәрлегенең әйләнеше чикләнгән (андый мөлкәтне, андый мөлкәт урнашкан һәм аларны куллану ихтыяҗы булган җир кишәрлекләрен алучы заттан тартып алынган объектны приватизацияләгән очракта);

13) гариза бирүче арендалаган мөлкәтне алуга өстенлекле хокукны файдаланудан баш тарту турында язмача гариза җибәргән;

14) гариза бирүче тапшырган белешмәләр ведомствоара арадашлык кысаларында алынган һәм (яки) хезмәт күрсәтүче орган карамагында булган белешмәләргә туры килми.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, Министрлык мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән формада.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене профильләү;

2) гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати арадашлык;

4) мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар (күрсәтүдән баш тарту) кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) (алга таба - бәяләү процедурасы);

5) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

6) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

Дәүләт хезмәте алдан эшләү (проактив) режимында күрсәтелми.

3.2. Гариза бирүченең профилен билгеләү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү Министрлыкта, МФЦда, Бердәм портал, Республика порталы, «Имущество» ЕИС аша, гаризаның документар формасын (мөрәҗәгать итүче тапшырган документларны) карау аша гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) билгеләүгә (мөрәҗәгать итүченең 159-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында билгеләнгән таләпләргә туры килүе һәм аларның Татарстан Республикасы мөлкәте булган күчемле һәм күчемсез милекне арендалау фактын ачыклау) юнәлдерелгән.

3.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүченең категориясен (билгеләрен) ачыклау ысуллары һәм тәртибе:

- гариза бирүчедән сораштыру (телдән анкета);

- гариза бирүче тапшырган документларны (белешмәләрне) карау;

- гариза бирүченең Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» эксперт системасын узуы.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүчене профильләү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүченең билгеләре күрсәткечләренең тулы исемлеге билгеләнә, аларның һәркайсы мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу өчен тапшырырга тиешле документларның билгеле бер исемлегенә туры килә.

Гариза бирүчеләрнең категория идентификаторы (билгеләре) бу Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән.

3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гаризаны һәм документларны кабул итү

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формасы әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеге мөрәҗәгать итүченең категориясе (билгеләре) нигезендә, шулай ук

күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматны бирү ысуллары әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

3.3.2. Шәхесне ачыклау (идентификация) ысуллары булып түбәндәгеләр санала:

- Министрлыкта, МФЦда – шәхесне раслаучы документ;

- документларны почта аша тапшырганда – шәхесне раслаучы тиешле тәртиптә таныклауган документ күчермәсе;

- документларны Бердәм портал, Республика порталы, «Имущество» ЕИС тапшырганда - Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы, шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза, көчәйтелгән квалификацияләнмәгән электрон имза, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм электрон формада хезмәт күрсәтүләрдә кулланыла торган тикшерү ачкычы сертификаты.

3.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

3.3.5. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә аның яшәү урынына яки тору урынына (физик затлар өчен, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп) яки урнашу урынына (юридик затлар өчен) бәйсез рәвештә күрсәтелә.

3.3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле наризаны һәм документларны регистрацияләү срогы әлеге Регламентның 2.7.1 – 2.7.4 пунктларында күрсәтелгән.

3.4. Ведомствоара мәгълүмати арадашлык

3.4.1. Гаризаларны җибәрү өчен нигез булып мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы һәм мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентка 3 нче кушымта таблицасының 2 бүлегендә күрсәтелгән документларны тапшырмавы тора.

Ведомствоара мәгълүмат соравы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан күрсәтелгән органнарга җибәрелә.

3.4.2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Бүлек белгече “Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша түбәндәге мәгълүмати запросларны сорый:

1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында белешмә (алга таба – ЕГРЮЛ) Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ).

2. Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында белешмә (алга таба – ЕГРИП), ТР буенча ФСХИдан.

3. Гариза бирүче булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты турында Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан (алга таба – ЕРСМСП) белешмә, ТР ФСХИдан.

4. Түләүле тартып алу каралган күчемсез мөлкәт турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (алга таба – ЕГРН) - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең идарәсеннән (алга таба - ТР буенча Росреестр).

5. Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле органыннан (алга таба – һәйкәлләрне саклау органы) мөлкәтнең Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) кертелүе турында белешмә (күчемсез мөлкәт өчен) – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан (алга таба – ТР Комитеты); түләүле тартып алу каралган күчемсез милек Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) караган булса.

3.4.3. Ведомствоара мәгълүмат запросы күрсәтелгән органнарга гаризаны һәм гаризага кушып бирелгән документларны теркәү көнендә мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) алар сакланган органнардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителгән кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында” 2021 елның 23 июнендәге № 963 карары нигезендә тиешле запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмаган вакыт эчендә электрон рәвештә бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин түгел;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның 7² статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомостводара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе).

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.

3.5. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш)

3.5.1. Бәяләү процедурасы атамасы һәм дәвмлылыгы

Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган мөлкәтнең базар бәясен билгеләүгә бәйсез бәя бирү. Бәяләү процедурасының дәвамлылыгы - гаризаны теркәгән көннән алып ике ай (дәүләт хезмәтен күрсәтү срогына керми).

3.5.2. Бәяләү процедурасы уздыручы субъектлар

«Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге № 135-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә эшчәнлек алып баручы бәйсез бәяләүче.

3.5.3. Бәяләү процедурасы объекты (объектлары)

Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган мөлкәт

3.5.4. Бәяләү процедурасын уздыру урыны

Бәяләү процедурасы бәяләү объекты булган урында башкарыла.

3.5.5. Бәяләү процедурасы нәтиҗәсе булган документ атамасы

Объектны бәяләү турында хисап.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү

3.6.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

3.6.2. Әгәр мөрәҗәгать итүче 159-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә һәм (яисә) гаризада күрсәтелгән арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашыру тәртибендә тартып алу 159-ФЗ номерлы Федераль закон яисә башка

федераль законнар нигезендә рөхсәт ителмәсә, Министрлык гаризаны алган көннән алып утыз көн эчендә аны мөрәҗәгать итүчегә кайтара, арендага бирелә торган мөлкәтне сатудан баш тарту сәбәпләре дә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән формада.

3.6.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, Министрлык бәяләү объектын бәяләү турындагы хисап һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән кергән белешмәләр нигезендә:

арендалана торган мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карарны аны бәяләү турында хисап кергән көннән алып ике атна эчендә кабул итә;

мөрәҗәгать итүчегә арендалана торган мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә арендалана торган мөлкәтне сату-алу шартнамәсе проектын җибәрә.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен күрсәтү (кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне түләүле тартып алу турындагы карар - мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) Бердәм порталда, Республика порталында, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетына көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше автомат рәвештә җибәрелә;

Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) мөрәҗәгать итү көнендә бирелә;

МФЦга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә)) мөрәҗәгать ителгән көнне электрон документ рәвешендә, Министрлык тарафыннан җибәрелгән, кәгазьдә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсендә бирелә.

3.7.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә аның яшәү урынына яки тору урынына (физик затлар өчен, индивидуаль эшкуарларны да кертеп) яки урнашу урынына (юридик затлар өчен) карамастан тапшырыла.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

Техник мөмкинлеге булганда, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча аның запросы статусы үзгәрүе (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле адымнар һәм гамәлләр турында санап үтелгән ысулларның берсе ярдәмендә хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат аша;

– Республика порталы аша;

– ЕИС «Имущество» аша;

– башка сервислар һәм ысуллар кулланып (булса).

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм
урта эшмәкәрлек субъектлары
тарафыннан арендалана торган күчемле
һәм күчемсез мөлкәтне, аларның
арендаланган мөлкәтне сатып алуга
өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып,
милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (https:// www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
2. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
3. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) - Реестр);
4. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы – ЕИС «Имущество» (http://lk.eisestate.tatar.ru);
5. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры – Хезмәт күрсәтүләр реестры;
6. Татарстан Республикасы Жир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы – Министрлык;
7. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – МФЦ.
8. «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге һәм кече, урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 22 июль, 2008 ел, № 159-ФЗ Федераль закон - № 159-ФЗ Федераль закон.

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторы

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карар | № 159-ФЗ Федераль законның 3 статьясына белән билгеләнгән таләпләр туры килүче, Татарстан Республики мөлкәте булган күчемле һәм күчемсез милек арендаторы булган шәхси эшмәкәрләр | 1А |
| 2. | | № 159-ФЗ Федераль законның 3 статьясына белән билгеләнгән таләпләр туры килүче, Татарстан Республики мөлкәте булган күчемле һәм күчемсез милек арендаторы булган юридик затлар | 2А |
| 3. | | гариза бирүче вәкиле | 3А |

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группа документлары саны | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| 1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүче үзе тапшырырга тиешле документлар | | | |
| 1. | 1А-3А | кәгазь документ формасындагы гариза | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| | | электрон формадагы гариза | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла) |
| 2. | 1А, 3А | Шәхесне раслаучы документ | МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 1А, 3А | Шәхесне раслаучы документ күчермәсе | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | иткәндә |
| 4. | 3А | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ | МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 5. | 3А | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 6. | 2А, 3А | Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алу турында мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле идарә органы карары күчермәсе | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 7. | 2А, 3А | Акционерлар реестрыннан өземтә (акционерлык җәмгыятьләре өчен) | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 8. | 2А, 3А | Юридик затның гамәлгә кую документлары күчермәсе | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | иткәндә |
| 2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, дәүләт хезмәте күрсәтелү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра алган документлар | | | |
| 1. | 2А, 3А | гариза бирүче булган юридик зат турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ) | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 2. | 1А, 3А | Гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмә (алга таба – ЕГРИП), ТР буенча ФСХИдан | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 1А-3А | Гариза бирүче булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты турында Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан (алга таба – ЕРСМСП) белешмә, ТР ФСХИдан | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 4. | 1А, 3А | Түләүле тартып алу каралган күчемсез мөлкәт турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан өземтә - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең идарәсеннән (алга таба - ТР буенча Росреестр). | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | 1А-3А | Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле органыннан (алга таба – һәйкәлләрне саклау органы) мөлкәтнең Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) кертелүе турында белешмә (күчемсез мөлкәт өчен) – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан (алга таба – ТР Комитеты); түләүле тартып алу каралган күчемсез милек Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) караган булса. | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группадагы документлар саны |
|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А-3А | документларны башка вәкаләтле органга тапшыру - гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү кермәгән органга бирелгән |
| 2. | 1А-3А | әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау |
| 3. | 1А-3А | гариза бирүче тапшырган документлар (шәхесне раслаучы документлар, вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документлар) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән моментка көчен югалткан |
| 4. | 1А-3А | гариза бирүче тапшырган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистартулар һәм төзәтүләр бар |
| 5. | 1А-3А | электрон формада тапшырылган документларда бозылган урыннар булуы хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматны тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми |
| 6. | 1А-3А | гариза формасында юлларның тулысынча тутырылмавы, |

| | | |
|---|---|---|
| | | шул исәптән, Бердәм порталда, Республика порталындагы интерактив формадагы гаризаны |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк | | |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А - 3А | гариза бирүче хезмәт күрсәтелү хокукына ия булган затлар рәтенә керми, шул исәптән, № 159-ФЗ Федераль законның 3 статьясы белән билгеләнгән таләпләргә туры килми |
| 2. | 1А - 3А | хезмәт күрсәтү турындагы запроста күрсәтелгән мәгълүматлар күчемсез милек арендасы шартнамәсендәге мәгълүматка туры килми |
| 3. | 2А, 3А | гариза бирүченең вәкаләтле идарә органының арендаланган мөлкәтне милеккә алу карары булмау |
| 4. | 2А, 3А | гариза бирүче (юридик зат – акционерлык җәмгыяте) тапшырган акционерлар реестры өземтәсе акционерлар һәм аларның өлешләре турында мәгълүмат бирми |
| 5. | 1А - 3А | запрос вәкаләтле булмаган зат тарафыннан тапшырылган |
| 6. | 1А-3А | арендаланган мөлкәт кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты гариза биргән көнне андый мөлкәткә шартнамә яки шартнамәләр нигезендә күчемсез милек өчен - ике ел яки аннан да күбрәк вакытта, күчемле милек өчен бер ел яки аннан да күбрәк вакытта аның вакытлыча кул астында һәм файдалануында яки вакытлыча файдалануда булса (каралган күчемсез яки күчемле милек кече яки урта эшмәкәрлек субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән, № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясында 4 кисәге буенча расланган исемлеккә кертелмәгән очракларда) |
| 7. | 1А-3А | арендаланган мөлкәт № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясында 4 кисәге буенча расланган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты гариза биргән көннән башлап күчемсез милек өчен – биш ел, күчемле милек өчен гариза биргәннән соң өч елга кадәр кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек итеп һәм (яки) файдалануга бирергә билгеләнгән исемлеккә кертелгән |
| 8. | 1А-3А | арендаланган мөлкәт № 209-ФЗ Федераль законның 18 |

| | | |
|---|---|---|
| | | статьясында 4 кисәге буенча расланган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты гариза биргән көннән башлап күчемсез милек өчен – биш ел, күчемле милек өчен гариза биргәннән соң өч елга кадәр кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек итеп һәм (яки) файдалануга бирергә билгеләнгән исемлеккә кертелгән |
| 9. | 1А-3А | гариза бирүче мөрәҗәгать иткән моментка № 159-ФЗ Федераль законның 4 статьясында 9 кисәгендә күрсәтелгән мөлкәтне алу хокукын югалткан |
| 10. | 1А-3А | күчемсез яки күчемле мөлкәт объекты № 159-ФЗ Федераль законның 1 статьясының 2 кисәге белән билгеләнгән чикләүләргә туры килә |
| 11. | 1А-3А | гариза бирүченең арендаланган милекне алуга өстенлекле хокукларын гамәлгә ашыру турында гариза бирү көнендә (күрсәтелгән күчемле, күчемсез милек № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясында 4 кисәге буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек итеп һәм (яки) файдалануга бирергә билгеләнгән дәүләт милке исемлегенә кертелгән очракта), арендаланган мөлкәтне сату-алу шартнамәсе төзелгән көндә (күрсәтелгән күчемле, күчемсез милек № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясында 4 кисәге буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек итеп һәм (яки) файдалануга бирергә билгеләнгән дәүләт милке исемлегенә кертелмәгән очракта) күчемле һәм күчемсез милекне арендалау түләве буенча, вакытында түләмәү (штрафлар, пенялар) бурычлары бар |
| 12. | 1А-3А | җир кишәрлегенең әйләнеше чикләнгән (андый мөлкәтне, андый мөлкәт урнашкан һәм аларны куллану ихтыяҗы булган җир кишәрлекләрен алучы заттан тартып алынган объектны приватизацияләгән очракта) |
| 13. | 1А-4А | гариза бирүче арендалаган мөлкәтне алуга өстенлекле хокукны файдаланудан баш тарту турында язмача гариза җибәргән |
| 14. | 1А-4А | гариза бирүче тапшырган белешмәләр ведомствоара арадашлык кысаларында алынган һәм (яки) хезмәт күрсәтүче орган карамагында булган белешмәләргә туры килми |

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

________________________________________

Арендаланган мөлкәтне алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашыру турында
ГАРИЗА

«____» _________ _____ ел ______________

Гариза бирүче__________________________________________________
(гариза бирүче юридик затның тулы атамасы)

_________________________________________________________________
(гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисеисеме һәм паспорт мәгълүматы)
_______________________________________________ нигезендә эш йөртүче,
(наименование документның атамасы)
_____________________________________________________ йөзендә,
(фамилия, исеме, әтисе исеме, вазыйфа)
«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше турында» 2007 ел, 24 июль, № 209-ФЗ Федераль законның 4 статьясы белән билгеләнгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары категориясенә кертү шартларына туры килүе турында хәбәр итә һәм Татарстан Республикасы мөлкәте булган

___________ № ___________ аренда шартнамәсе нигезендә арендаланган
____________________________________________________________,
(күчемсез объектның атамасы, тасвирламасы, адресы, мәйданы),
бирүне сорый.

Сатып алына торган мөлкәт өчен түләүне ___ айга кичектереп торуны сорый.

Әлеге гаризага исемлектә күрсәтелгән документлар теркәлә.

**Гариза бирүченең адресы һәм банк реквизитлары:**

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- җибәрергә ______________________________________________________;

(күрсәтелә: электрон документ формасында МФЦга, электрон документ экземпляры рәвешендә кәгазьдә; Республика порталында шәхси кабинетка, ЕИС «Имущество»га);

- Министрлыкка бирергә ____________________

_____________________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь документ формасында, электрон документ формасында яки электрон документ экземплярына рәвешендә кәгазьдә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында телефон аша уздырылган сораштыруда телефон аша катнашырга ризалыгымны бирәм: _______________________.

Гариза бирүченең (бирүчеләрнең) (вәкилнең (вәкилләрнең) ___________ №________________

_______________________________________/_______________________ышанычнамә буенче /

(вәкилнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булса) имзасы)

М.П.(мөһер булса)

Гариза кабул ителде: "___"__________ 20__ г.

_______/____________________/гаризаны кабул итеп алучы белгечнең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Элемтә өчен телефон ______________

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Рекомендуемая форма

Боерык

Дата ________________________ № ______________

Татарстан Республикасы милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъекты арендалый торган мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында

Дәүләт мөлкәте арендаторының мөрәҗәгатенә бәйле ____________ ___________________________________(аренда шартнамәсе _________________),
(сатып алучы арендаторның атамасы) (шартнамә реквизитлары)
аның арендаланган мөлкәтне алуга өстенлекле хокукларын гамәлгә ашыру максатларыннан, «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге һәм кече, урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 22 июль, 2008 ел, № 159-ФЗ Федераль законның 3, 4 статьяларына таянып:

1. Арендаторга дәүләт мөлкәтен реализацияләү юлы белән

_____________________________________________________________
(дәүләт мөлкәтен сатып алучы арендаторның атамасы)
дәүләт мөлкәтен приватизацияләүне гамәлгә ашырырга___________________________________________ (алга таба – Объект)
(мөлкәтнең атамасы, мәйданы, адресы)

2. Объектның бәйсез бәяләүче

_____________________________________________________________
(бәйсез бәяләү оешмасы атамасы)
билгеләгән базар бәясен расларга _________________ (____________________________________________________________) сум.
(сумма цифрларда һәм язмача)
(бәяләү турында _____________________________).
(бәяләү отчетының реквизитлары)

3. ________________________________________________________
(дәүләт мөлкәтен сатып алучы арендаторның атамасы)
сатып алына торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп торырга мөмкин.
____________________шарты белән кичектереп тору срогы _______________
(кичектереп тору срогы)

беренче взнос Объектның әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән базар бәясенең __________________________________өлешеннән ким булмаска тиеш.
(беренчел взнос суммасы)

4. Мөлкәт идарәсенә (_________________________) 10 көн эчендә әлеге карарны, шартнамәне
_____________________________________________________________________________
(шартнамә төре: арендаланган мөлкәтне сату-алу)
_____________________________________________________________________________
(дәүләт мөлкәтен сатып алучы арендаторның атамасы)
юллауны тәэмин итәргә.

5. Сатып алучыга әлеге карарны алганнан соң 30 көн эчендә арендаланган мөлкәтнең сату-алу шартнамәсен имзалауны һәм Татарстан Респубилкасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына юллауны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ___________________________йөкләргә.

Министр ________________

Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

(Орган бланкы)

Боерык

Дата ________________________ № ______________

Татарстан Республикасы милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган мөлкәтне, өстенлекле хокукта алу мөмкинлеген тормышка ашырып, хосусыйлаштырудан баш тарту турында

«Дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне, аларның арендаланган милекне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырып, шәхси мөлкәткә бирү» хезмәте буенча ______________№________________гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны карап чыгу нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органының расланган административ регламенты нигезендә карар кабул ителде ___________________________________.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәрләренә ачыклык кертү:

____________________________________________________________________;

____________________________________________________________________;_____________________
_________________________________________________;_______________________________________
_____________________________.

Өстәмә рәвештә мәгълүмат бирәбез: ______________________________________.

Сез күрсәтелгән кимчелекләрне төзәткәннән соң _________________________ хезмәт күрсәтү турында гариза белән кабат мөрәҗәгать итә аласыз.

Әлеге баш тартуны судка кадәр ____________________ дәүләт хезмәте күрсәтү өчен вәкаләтле булган органга шикаять итәргә мөмкин, судлашу тәртибендә дә шикаять итәргә була.

Вазыйфа ______________________ (Фамилия, инициаллар)

(имза)